РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«4» сентябрь 2019 ел г. Альметьевск № 1636

Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 08 декабрь 2017ел №1955 «Авиация эшләре, парашюттан сикерү, бәйләнгән аэростатларны күтәрү, һава судноларының демонстрацион очыш ясаулары, пилотсыз очу аппаратларының очышы, шулай ук Әлмәт муниципаль районы территориясе өстендә аэронавигация үткәрү турындагы мәгълүматларда күрсәтелмәгән торак пункт чикләрендә урнашкан мәйданнарга төшү һәм күтәрелү хакында административ регламентны раслап рөхсәт бирүче муниципаль хезмәт турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив актны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 08 декабрь 2017 ел № 1955 «Авиация эшләре, парашюттан сикерү, бәйләнгән аэростатларны күтәрү, һава судноларының демонстрацион очыш ясаулары, пилотсыз очу аппаратларының очышы, шулай ук Әлмәт муниципаль районы территориясе өстендә аэронавигация үткәрү турындагы мәгълүматларда күрсәтелмәгән торак пункт чикләрендә урнашкан мәйданнарга төшү һәм күтәрелү хакында административ регламентны раслап рөхсәт бирүче муниципаль хезмәт турында» карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2018 ел 9 октябрендәге №1604 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5.1.пункт, 5.1.1., 5.1.2.пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.Муниципаль хезмәт алучылар судка кадәр район башкарма комитетына Төзелеш идарәләре, элемтә, транспорт һәм юл хуҗалыгы,

Зак. № 3063

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк һәм 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган төрле оешма хезмәткәреннән, шикаятьне карауларын сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Түбәндәге очракларда, шулай ук, шикаять белдерергә мөмкин:

5.1.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча үтенечне регистрацияләүнең вакыты бозылу, Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән ихтыяҗның канәгатьләндерелмәве;

5.1.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү үтенечне регистрацияләүнең срогы бозылу. Күрсәтелгән очракта судка кадәр (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарлары һәм эшләреннән, әгәр дә аларга 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе 1.3 бүлегендә каралган муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә йөкләнгән булса, шикаятьне карауларын сорап мөрәҗәгать итә».

5.1.5. пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«5.1.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту Федераль законнарга, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актларына, Россия Федерациясе субъектларының башка төр норматив хокукый актларына, муниципаль хокукый актларга нигезләнмәгән булса. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), әлеге Федераль законның 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү вазифасы тулысынча йөкләнгән булса, әлеге очракта күпфункцияле үзәк хезмәткәренә судка (судтан тыш)кадәр шикаять бирелергә мөмкин».

5.1.7. пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«5.1.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның хезмәт вазифаларын башкаручысы, күпфункцияле үзәк, әлеге 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралганча оешма яисә аларның хезмәткәрләреннән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлыклар һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төр төзәтмәләрнең билгеләнгән вакыты бозылу. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), әлеге 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү вазифасы тулысынча йөкләнгән булса, әлеге очракта күпфункцияле үзәк хезмәткәренә судка (судтан тыш)кадәр шикаять бирелергә мөмкин".

5.1.8., 5.1.9. пунктчалары өстәргә:

«5.1.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу»;

5.1.9. Әгәр туктату нигезләре Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), әлеге 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү вазифасы тулысынча йөкләнгән булса, әлеге очракта күпфункцияле үзәк хезмәткәренә судка (судтан тыш)кадәр шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. пунктны 5.2.1, 5.2.2, 5.2.3 пунктчалары белән тулыландырырга:

«5.2.1. Шикаять кәгазьдә язмача, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүче органга яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәк яисә дәүләт хакимиятенең халыкка хокукый белем бирүне оештыручы (алга таба - күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы) органына (җирле үзидарә органына), шулай ук әлеге Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга (булган очракта) бирелә яисә турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючының вәкаләтле вазифаи затка тапшырыла. Әлеге 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралганча, оешма хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге оешма җитәкчеләренә бирелә;

5.2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү органы, дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү органы җитәкчесе, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган җитәкчеләренең, муниципаль хезмәткәргә почта аша, информацион-технологик “Интернет”челтәренең күпфункцияле үзәге аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче оешманың рәсми сайты аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче бердәм порталы, яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче төбәк порталы, шулай ук, шикаять белдерүчене шәхси кабул иткәндә, карарларына, эшләренә (эшләмәүләренә) карата шикаятьләр. Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә почта аша, информацион-технологик “Интернет” челтәренең күпфункцияле үзәге, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче оешманың рәсми сайты аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче бердәм порталы, яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче төбәк порталы, шулай ук, шикаять белдерүчене шәхси кабул иткәндә, карарларына, эшләренә (эшләмәүләренә) карата шикаятьләр. 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе, 1.1. бүлегендә каралган оешма хезмәткәрләренә почта аша, информацион-технологик “Интернет” челтәренең күппрофельле үзәге аша, муниципаль хезмәт күрсәтүче оешманың рәсми сайты аша, муниципаль хезмәт күрсәтүче бердәм порталы, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче төбәк порталы, шулай ук, шикаять белдерүчене шәхси кабул иткәндә, карарларына, эшләренә (эшләмәүләренә) карата шикаятьләр.

5.2.3.Федераль органнарның башкаручы властьлары, дәүләт корпорацияләре һәм аларның җитәкчеләре, федераль дәүләт хезмәткәрләре, Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды җитәкчеләре, 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе, 1.1. бүлегендә каралган оешма һәм аның хезмәткәрләре, шулай ук, күпфункцияле үзәк һәм аның хезмәткәрләренең карарларына, эшләренә (эшләмәүләренә) карата шикаятьләр бирү тәртибе һәм аларны карау Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә».

5.3. пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү органнарына, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк оештыручыларына, Федераль законның 16 маддәсе, 1.1. бүлегендә каралган оешмаларга, яисә югары оешмага (булган очракта)кергән шикаятьләр теркәлгәннән соң, унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш. Дәүләт хезмәте күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы, күпфункцияле үзәк, 2010 ел 27 июлендәге №210 Федераль законның 16 маддәсе, 1.1.

бүлегендә күрсәтелгән оешмалар муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы документларда җибәргән хаталарын, ялгышларын төзәтүдән баш тартсалар яисә билгеләнгән вакытта төзәтмәсәләр, шикаятьләр теркәлгәннән соң, биш эш көне эчендә каралырга тиеш».

5.4.1., 5.4.2., 5.4.3., 5.4.4.пунктларын түбәндәгечә бәян итәргә:

«5.4.1. Хезмәт күрсәтү оешмасының, хезмәт күрсәтү оешмасы җитәкчесенең яки муниципаль хезмәткәрнең исеме, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең исеме;

5.4.2. Шикаять белдерүчегә җавап җибәрү өчен шикаять бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме(соңгысы – булган очракта), шикаять бирүче физик затның яшәү урыны турында белешмә, яисә юридик затның кайда урнашканлыгы турында белешмә, контакт өчен телефон номеры, адресы, электрон почтасы (булса);

5.4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче оешма, аларның җитәкчеләре, яки муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, эшләренә(эшләмәүләренә) карата шикаятьләр турында белешмә;

5.4.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүче оешма, аларның җитәкчеләре, яки муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары, эшләре (эшләмәүләре) белән канәгать булмавына дәлилләр».

5.7. пунктның 5.7.1., 5.7.2.пунктчаларын түбәндәгечә бәян итәргә:

«5.7. Каралган шикаять нәтиҗәләреннән соң түбәндәге ике карарның берсе кабул ителә:

5.7.1.Кабул ителгән карарны кире кагу, муниципаль хезмәт органнары биргән документларда ясалган хаталарны, ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары нигезендә алу күздә тотылмаган булса, акчаларын кайтарып бирү формасы белән шикаятьләр канәгатьләндерелә;

5.7.2.Шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла».

5.8. пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне тикшерү, карау барышында административ хокук бозулар, яисә җитәкче тарафыннан эшләнгән җинаятьләр ачыкланса, әлеге эшләрне карау хокукына ия хезмәткәр кичекмәстән материалларны прокуратура органнарына юллый».

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольга алуны район башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары А.Ә. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы — М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ